**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 сентябрь № 671

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 декабрь, 976 нчы, 2015 ел, 29 апрель, 299 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Ярдәмче программалар исемлеге» юлына «2015 – 2022 елларга транспорт тармагында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» ярдәмче программасын өстәргә;

Ярдәмче программаның 1 бүлегендә 1.5.3 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.3. Транспорт тармагында энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү

Татарстан Республикасы транспорт тармагының энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләре нигездә россия икътисадының энергия нәтиҗәлелеге дәрәҗәсенә туры килә. Моның төп сәбәпләре – искергән технологик җиһазларны һәм транспорт техникасы паркын эксплуатацияләү, шулай ук энергия куллану культурасының түбән булуы, кулланучыларны стимуллаштыручы факторлар булмау һәм чит илдәге

күпчелек энергетика ресурсларына бәяләр белән чагыштырганда ягулык-энергетика ресурсларына чагыштырмача түбән бәяләр җирлегендә файдаланган энергия ресурслары өчен түләү системасының нәтиҗәле булмавы.

Татарстан Республикасының ТТП энергия сыйдырышлыгы уртача дөньякүләм дәрәҗәдән 1,5 тапкырга югары һәм алга киткән илләрдән 2 – 2, 5 тапкыр югары. Сәнәгатьнең энергия сыйдырышлыгы буенча Татарстан Республикасы АКШ, Япония һәм Европаның үсеш алган илләреннән 2 – 3 тапкырга калыша. Энергия сыйдырышлыкның югары күрсәткечләрен саклау республиканың икътисади үсешен тоткарлаучы фактор булып тора.

15.1 таблицада «транспорт һәм элемтә» тармагы буенча 2012 елда ягулык-энергетика ресурсларын куллану күләмнәре китерелгән (Татарстан Республикасы). Татарстан Республикасы икътисадының гомуми структурасында «транспорт һәм элемтә» тармагы өлеше 6,6 процент тәшкил итә.

Энергия саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның өстенлекле юнәлешләренең берсе булып транспорт тармагының энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү тора.

15.1 таблица

«Транспорт һәм элемтә» тармагы буенча 2012 елда ягулык-энергетика ресурсларын куллану күләмнәре

(шартлы ягулык, тонна)

| Тармак исеме | Газ | Мазут | Күмер | Бензин | Дизель ягулыгы | Электр энергиясе | Җылылык энергиясе | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Икътисад – барлыгы | 15 110 514 | 110 878 | 9 396 | 204 395 | 996 544 | 2 695 997 | 3 834 918 | 22 962 642 |
| Транспорт һәм элемтә | 812 961 | 345 | 505 | 49 853 | 323 693 | 281 432 | 44 236 | 1 513 025 |

Республикада төп транспорт төрләре булып тимер юл, һава, эчке су һәм автомобиль транспорты тора. ТТПда «транспорт» тармагының тулаем өстәмә бәясе өлеше 2013 елда 12,3 процент тәшкил итте. Икътисад үсешен тулаем исәпкә алганда, транспорт өлкәсендә энергия куллану шулай ук даими үсә һәм үсеш темплары буенча сәнәгать тармагыннан гына калыша.

Транспорт оешмаларының ягулык куллану структурасы 15.2 таблицада китерелгән.

15.2 таблица

Транспорт оешмаларының ягулык куллануы

| Ягулык төре | 2011 ел | 2012 ел | 2012/ 2011 еллар, процент | Табигый чагылышта артым | 2013 ел | 2013/ 2012 еллар, процент | Табигый чагылышта артым |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Авиация бензины, мең тонна | 0,2 | 0,1 | 50 | -0,1 | 0,1 | 100 | 0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Автомобиль бензины, мең тонна, | 38,3 | 30,4 | 79 | -7,9 | 27,1 | 89 | -3,3 |
| шул исәптән авто-транспорт эшенә, мең тонна | 37,5 | 30,3 | 81 | -7,2 | 25,6 | 84 | -4,7 |
| Дизель ягулыгы, мең тонна, | 274,6 | 322,3 | 117 | 47,7 | 269,4 | 84 | -52,9 |
| шул исәптән авто-транспорт эшенә, мең тонна | 161,3 | 165,6 | 103 | 4,3 | 148,6 | 90 | -17 |
| Керосин, мең тонна | 57,8 | 49,3 | 85 | -8,5 | 63,7 | 129 | 14,4 |
| Табигый янучы газ, млн.куб.метр, | 731,4 | 686,7 | 94 | -44,7 | 738,3 | 108 | 51,6 |
| шул исәптән авто-транспорт эшенә, млн.куб.метр | 0,7 | 1,5 | 214 | 0,8 | 5,9 | 393 | 4,4 |
| Сыекландырылган газ, млн.куб.метр, | 23,7 | 24,3 | 103 | 0,6 | 26,2 | 108 | 1,9 |
| шул исәптән авто-транспорт эшенә, млн.куб.метр | 23,5 | 24,1 | 103 | 0,6 | 23,9 | 99 | -0,2 |

Автотранспорт чараларына мотор ягулыгы сыйфатында нигездә тонык нефть продуктлары кулланыла (автомобиль бензины һәм дизель ягулыгы).

15.3 таблица

Бензин, дизель ягулыгы куллану

(мең тонна)

| Ягулык төре | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел |
|---|---|---|---|
| Автомобиль бензины | 179,7 | 183 | 253,9 |
| Дизель ягулыгы | 690,4 | 778,3 | 663,9 |

Татарстан Республикасы предприятияләре тарафыннан автомобиль бензинын куллану 2013 елда 253,9 мең тонна, дизель ягулыгын куллану 663,9 мең тонна тәшкил итте (15.3 таблица).

2013 елда бензин куллануның үсеш темпы 2012 ел белән чагыштырганда 139 процент тәшкил итте. 2013 елда үсеш – 7,9 мең тонна, 2012 елда 3,3 мең тонна тәшкил итте. Дизель ягулыгын куллану узган ел белән чагыштырганда 2013 елда 15 процентка кимегән, бу чакта кимү 114,4 мең тонна тәшкил итте.»;

Программага түбәндәге эчтәлекле «2015 – 2022 елларга транспорт тармагында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» ярдәмче программасын өстәргә:

«2015 – 2022 елларга транспорт тармагында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» ярдәмче программасы»

Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа исеме | 2015 – 2022 елларга транспорт тармагында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| Ярдәмче программа максатлары | Транспорт комплексында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү.<br>Транспорт комплексында ягулык һәм энергетика ресурсларын куллануны киметү |
| Ярдәмче программа бурычлары | Ягулык куллануны киметүгә юнәлдерелгән оештыру һәм техник чаралар үткәрү |
| Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре белешмә характерында һәм энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге өлкәсендә федераль һәм республика программалары кысаларында тиешле елга һәм планлаштырылган чорга бюджет проектын эшләгәндә ел саен тәгаенләнергә тиеш |
| Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | 2022 елда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелергә тиеш:<br>җәмәгать транспортына караган, анда йөртү буенча хезмәтләргә тарифларны җайга салуны Татарстан Республикасы гамәлгә ашырган, аларга мөнәсәбәттә энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча, шул исәптән транспорт чараларында мотор ягулыгы сыйфатында кулланылган бензинны һәм дизель ягулыгын мотор ягулыгы сыйфатында кулланылган табигый газ, газлы кушылмалар, сыеклаңдырылган углеводород газы һәм электр энергиясенә алыштыру буенча гамәлләр үткәрелгән транспорт чаралары саны – 423 берәмлек;<br>анда йөртү буенча хезмәтләргә тарифларны җайга салуны Татарстан Республикасы гамәлгә ашырган, мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ, газлы кушылмалар, сыеклаңдырылган углеводород газы кулланган транспорт чаралары саны – 3092 берәмлек |

Республиканың юл-транспорт тармагында энергия саклауны үстерү өчен предприятиеләр тарафыннан бер төркем чараларны гамәлгә ашыру планлаштырыла:

пассажирлар йөртүче җәмәгать транспортында альтернатив мотор ягулыгын куллануга күчү;

энергетик тикшерүләр үткәрү;

энергия саклаучы яктылык техник җайланмаларын куллануга кертү (гамәлдәге

люминесцент яктырткычларны утдиодлыларга алыштыру, яктылык чыганакларын сүндерүнең автоматлаштырылган системаларын урнаштыру);

транспорт комплексы объектларын (автоюллар, күперләр, юл үткәргечләр) төзекләндергәндә һәм төзегәндә заманча утдиодлы яктырту системаларын куллану;

электр белән җылытуны газ белән җылытуга алмаштыру;

ягып җылыту торбаларын алюминий регистрларга алмаштыру;

ягып җылыту системасын автоматик җайга салу системасын куллануга кертү;

ягып җылытуның парлы-тамчылы радиаторларын урнаштыру;

биналарны җылылык белән тәэмин итү системасында исәпкә алу һәм көйләү үзәкләрен урнаштыру;

конденсатор җайланмаларын монтажлау;

асфальт-бетон япмаларны җәю һәм төзәтүнең яңа технологияләрен үзләштерү;

автотранспортта мониторинглау һәм тикшерүдә тоту системаларын урнаштыру (ГЛОНАСС, ягулык исәпләү датчиклары).

Юл-транспорт комплексы предприятиеләрендә билгеләп куелган чараларны тормышка ашыру җитештерүнең энергетик нәтиҗәлелеген арттырырга, продукция җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен ягулык-энергетика ресурсларын чагыштырма куллану күрсәткечен киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Транспорт тармагында энергия ресурсларын куллануны киметү һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шулай ук автомобиль транспортының әйләнә-тирә мохитка тискәре йогынтысы дәрәҗәсен киметүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы тормышка ашырыла, аның кысаларында җәмәгать транспортының 50 процентын, коммуналь техниканың 30 процентын, төзелеш техникасының 30 процентын газ-мотор ягулыгын куллануга күчерү планлаштырыла.

ТТПның энергия сыйдырышлылыгының югары әһәмиятен исәпкә алып, транспорт чараларын мотор ягулыгының отышлырак төренә күчерү зарурлыгы туды. Мондый ягулык сыйфатында компримирлашкан табигый газны файдалану иң яраклысы. Продукциянең (товарларның, хезмәтләрнең) үзкыйммәтендә мотор ягулыгын сатып алуга чыгымнар 30 проценттан артып китү мөмкинлеген исәпкә алып, мотор ягулыгының арзанлырак альтернатив төрен куллану (1 куб.метр компримирлашкан табигый газның бәясе республика буенча 1 литр дизель ягулыгы бәясеннән 3,6 тапкырга кимрәк) предприятиеләр һәм оешмалар өчен мөһим социаль-икътисади әһәмияткә ия.

Ягулыкның төрле вариантларын кулланучы, нормада 100 км.га 40 л. ягулык бетерүче автомобиль транспорты өчен 100 км йөрү бәясен чагыштыру күрсәткәнчә, метан дизель ягулыгыннан һәм бензиннан 3 тапкыр, пропан-бутаннан 2 тапкыр арзанрак.

Әлеге чараны тормышка ашыру республикада икътисадны үстерүгә тулаем алганда уңай йогынты ясый, тотрыклылыкка һәм озак вакытлы инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм итәчәк.»;

«2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына 1 нче кушымтадагы таблицага түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| «9 бурыч. Транспорт комплексында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2014 – 2022 елларга транспорт комплексында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү | Җәмәгать транспортына караган, анда йөртү буенча хезмәтләргә тарифларны җайга салуны Татарстан Республикасы гамәлгә ашырган, аларга мөнәсәбәттә энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү буенча, шул исәптән транспорт чараларында мотор ягулыгы сыйфатында кулланылган бензинны һәм дизель ягулыгын мотор ягулыгы сыйфатында кулланылган табигый газ, газлы кушылмалар, сыекландырылган углеводород газы һәм электр энергиясенә алыштыру буенча гамәлләр үткәрелгән транспорт чаралары саны, берәмлек | 62 | 82 | 91 | 161 | 192 | 220 | 250 | 283 | 327 | 380 | 423 |
| | Анда йөртү буенча хезмәтләргә тарифларны җайга салуны Татарстан Республикасы гамәлгә ашырган, мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ, газлы кушылмалар, сыекландырылган углеводород газы кулланган транспорт чаралары саны, берәмлек | 262 | 262 | 539 | 648 | 842 | 1142 | 1472 | 1832 | 2222 | 2642 | 3092». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\671.docx